ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш, Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш., Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 12 от «17» 01 2024 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 16 мартындагы 243 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Су кодексының 27 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 16 мартындагы «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен су объектларыннан файдалану кагыйдәләрен кабул итү турында» 243 номерлы карарына (алга таба- Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 1.5. пунктының 4 абзацында "агулы матдәләр" сүзләреннән соң (исемлеге Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган диңгез портлары территорияләрендәге, аммиак, метанол, аммиак селитрасы һәм калий нитраты махсус саклагычларыннан тыш, , яр буе саклау полосалары чикләреннән тыш,)" сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru// рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталына урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары А.Х.Әгъләмовка йөкләргә.

Җитәкче О.Н.Павлов

0000012